# *21 февраль –*
# *Халыкара туган тел көне*

# Шигырь сөйлим туган телемдә

Үз телемдә шигырь укыйм,
Үз телемдә сөйли алам.
Туган җирем, туган илем,
Мин бит синнән илһам алам.
Хәтта кошның да туган теле бар,
Теле булганның гына иле бар.
Бабаларымның иң зур мирасы,
Чиксез галәмнең гүя моңы син.
Яшә мәңгегә
И туган телем,
Былбыл моңыдай,

*Һәркемнең бар мәңгелектән*
*Дөньяга бар булган көне.*
*Кайсы чорда, кайчан микән*
*Халкыбызның туган көне –*
*Туган телнең туган көне?*
*Илнең теле ачылган көн,*
*Җанга моңнар тулган көне,*
*Илаһи вә илһамлыдыр*
*Туган телнең туган көне.*

*Ш.Галиев*

Организация Объединенных Наций по вопросам образования науки и культуры

***1999 нчы елның ноябрендә, Бангладеш дәүләте тәкъдиме белән, ЮНЕСКО Генераль конференциясе, ЮНЕСКОга кергән илләр һәм Берләшкән Милләтләр оешмасы 21 февраль көнен Туган тел көне дип игълан итте.***

***Беренче мәртәбә ул 2000 нче елның 21 февралендә Парижда ЮНЕСКО штаб-квартирасында тантаналы рәвештә билгеләп үтелде.***

***Ни өчен Халыкара туган тел көне итеп 21 февраль билгеләнгән соң?***

***Эш шунда: 1952 нче елның 21 февралендә Пакыстанда банглы теленә дәүләт теле статусы таләп итеп көрәшкән 5 студент үтерелгән була. Билгеле булганча, Пакыстанның көнчыгыш өлеше соңрак Бангладеш бәйсез дәүләтенә әйләнә.***

# Ана теле бер булыр

*Көндәлек тормышта без еш кына үзебез сөйләшә торган телне яки телләрне табигый бер нәрсә итеп кабул итәбез. Гаять зур әһәмияткә ия телебез тормыш-көнкүрешебезнең аерылгысыз бер өлеше булып тора. Фикерләү, тәртип һәм үзебезнең тормышыбызның рәвешенә, ысулына әйләнә. Шуңа күрә дә без аның төп функциясен - нәкъ менә* ***аралашу һәм аңлашу функциясен*** *онытып җибәрәбез. Бу тел - сабыйлык, изге гаилә тәҗрибәсе, башлангыч социаль мөнәсәбәтләр теле.*

*Дөньяда* ***6000*** *нән артык телдә сөйләшәләр. Аларның һәрберсе авазлар, мәгънәләр һәм грамматик кагыйдәләрнең катлаулы системасыннан тора.*

*Халыкара туган тел көнендә* ***барлык телләр дә тигез*** *дәрәҗәдә итеп таныла, чөнки һәр тел кеше халәтенә бердәнбер җавап һәм без сакларга тиеш* ***тере мирас*** *булып тора.*

**Коитиро Мацуура – ЮНЕСКО Генераль директоры**

*Җир йөзендә бүгенге көндә 6000 тел бар дип исәпләнә. Шулардан иң күп санлы кешеләр тарафыннан кулланыла торганы — кытай теле, бу телдә 1,2 млрд кеше сөйләшә,*
*инглиз телендә — 478 млн,*
*хинди телендә — 437 млн,*
*испанда — 392 млн,*
*рус телендә — 284 млн,*
*гарәптә — 225 млн,*
*португалда — 184 млн,*
*француз телендә 125 млн кеше сөйләшә.*



Туган телләр була бер генә –
Туган телнең кадрен бел генә.

**Татар теле – туган тел,**
**Безнең газиз булган тел.**
**Әти-әни, әби-бабай**
**Безне сөя торган тел.**

*Шәйхи Маннур*

Организация Объединенных Наций по вопросам образования науки и культуры

- Татар теле – ЮНЕСКО тарафыннан бөтендөнья халыкара аралашу теле дип саналган 14 телнең берсе:

***ИНГЛИЗ, НЕМЕЦ, ФРАНЦУЗ, ИСПАН, ИТАЛЬЯН, ПОРТУГАЛ, ГАРӘП, ФАРСЫ, РУС, КЫТАЙ, ТӨРЕК, ЯПОН, ҺИНД, ТАТАР ТЕЛЛӘРЕ***

- Татар телен белгән кеше 30 дан артык төрки халык белән җиңел аңлаша һәм аралаша ала

# Туган тел көне белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшинның котлавы

Бүген бездә зур бәйрәм – Туган тел көне. Республикабызда ул һәр ел саен бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның Туган көнендә билгеләп үтелә. Тукаебыз заманында телебезне хөрмәтләп-сөеп, "И туган тел, и матур тел, Әткәм-әнкәмнең теле! Дөньяда күп нәрсә белдем, Син туган тел аркылы.", - дип язган иде...

**Кадерле татарстанлылар!**

Бүген бездә зур бәйрәм – Туган тел көне. Республикабызда ул һәр ел саен бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның Туган көнендә билгеләп үтелә. Тукаебыз заманында телебезне хөрмәтләп-сөеп,

***"И туган тел, и матур тел,***
***Әткәм-әнкәмнең теле!***
***Дөньяда күп нәрсә белдем***
***Син туган тел аркылы."***, - дип язган иде...

Туган тел халыкның тарихын, рухын, ерак гасырлардан буыннан-буынга күчеп килүче гореф-гадәтләрне чагылдыра. Ул – җитди һәм сакчыл мөнәсәбәткә лаек, һәрьяклап сакланырга һәм үсәргә тиешле зур хәзинә. Сабый чактан алып өлкән яшькә кадәр туган телгә мәхәббәт, аның аһәңе белән хозурлану, мәдәният җәүһәрләренең кадерен белү мөһим.
Дуслык белән дан тоткан Татарстан җирендә йөздән артык милләт вәкиле яши. Мондый төрлелек республикабызга кабатланмас милли төсмер өсти. Татарстанда яшәүче халыклар арасында күпгасырлык аңлашу һәм хөрмәт традицияләре, туганлык һәм татулык хөкем сөрә. Татарстан Республикасы Президенты, Парламенты һәм Хөкүмәтенең тел өлкәсендә алып бара торган нигезле сәясәте республикада дәүләт милли сәясәтенең аерылгысыз өлешенә әверелде, ул ватандашларыбызның туган телне саклау һәм киләчәккә үстерү буенча сәяси һәм граждани хокукларын тәэмин итү турында Төп закон нормаларының һичшиксез үтәлүенә нигезләнә. Татарстанда законнар белән дә, гамәлдә дә һәр кешенең үз туган телен белү һәм туган телдә иркәле аралашу, мәдәният хәзинәләре белән таныш булу, үз халкыңның тарихын өйрәнү хокукый тәэмин ителгән. Республикада милли мәктәпкәчә балалар учреждениеләре челтәре үсә бара.
Халыкның этник төркемнәре өчен милли-мәдәни үзәкләр, үзешчән театрлар, китапханәләр һәм якшәмбе мәктәпләре эшли, халык иҗаты ярминкәләре һәм фестивальләре үткәрелә, фольклор бәйрәмнәр һәм йолалар яңартыла, традицион һөнәрчелек һәм кәсепчелек торгызыла...
Без тел һәм милләтара аралашу өлкәсендә позитив тенденцияләрнең алга таба туплану зарурлыгына нык ышанабыз, чөнки халыкларның этномәдәни тәңгәллеген, туган телләрен, мәдәни үзенчәлекләрен саклап калу, шулай ук яшь буынны борынгы бабаларның иң яхшы гореф-гадәтләренә турылыклы рухта тәрбияләү һәр милләтнең иң зур бурычы.
**Кадерле татарстанлылар!**
Туган тел көне -– һәркайсыбызга үзебезне туган халкыбызның бер өлеше итеп тою мөмкинлеген бирә торган бәйрәм. Тел – бер милләт вәкилләрен берләштерә торган, бербөтен итә торган ышанычлы корал ул. Газиз әниләребезнең бишек җыры яңгыраган, дөньяга иң беренче авыз салган һәм аны танып белергә өйрәткән тел!
Бәйрәм белән сезне, кадерле татарстанлылар! Туган тел көне белән!

**Тел –**

**халык күңеленең**

**кыңгыравы.**

**Ә кыңгырау -**

**кагылмасаң чыңламый.**

**Ф. Яруллин**

***383 тел бөтенләй юкка чыгарга мөмкин. Мәсәлән, Силец Дини телендә 1 кеше, Африка урманнарында яшәүче ючи кабиләсе телендә 5 кеше генә сөйләшә.***

***Белгечләр якындагы йөзьеллыкта барлык телләрнең 95% ы яшәүдән туктар дип фараз итә. Мәсәлән, бер ел эчендә 10 тел юкка чыга дигән фикер бар.***

***Европа илләрендә 123 телдән тугызы юкка чыккан, егерме алтысы югалу алдында тора, тагын 38 телгә шундый ук куркыныч яный.***





# Исчезающие языки России




Spacereal.ru

# Дөнья телләре атласы




Атлас языков мира. Происхождение и развитие языков во всем мире

***И туган тел,***

***и матур тел,***

***Әткәм-әнкәмнең***

***теле.***

***Г.Тукай***

***Туган җирем – Идел буе,***
***Һәркемнең бар туган иле.***
***Туган җирем кебек назлы,***
***Җырдай моңлы татар теле.***

*Яндың да син, туңдың да син,*

*Нишләтмәде язмыш сине.*

*Дөньяда күп нәрсә күрдең,*

*Әй мөкатдәс татар теле,*

*Әй син батыр татар теле!*

***Нәҗар Нәҗми***

***И минем җандай кадерлем***
***И җылы, тере телем!***

***Х.Туфан***

***Татарча да яхшы бел,***
***Русча да яхшы бел,***
***Икесе дә безнең өчен***
***Бик кирәкле, затлы тел.***

***Шәйхи Маннур***

***Туган тел ул –***
***Бездән соң да***
***Яшәр өчен туган тел.***
***Бүгенгедән киләчәккә***
***Дәшәр өчен туган тел.***

***Дәрдмәнд***

***Тел ул – буыннан-буынга ана сөте белән күчә килгән һәм күчәчәк мөкатдәс бер мирас.***

***Тел, ниһаять, туган ил, туган җир ул.***

***Х. Сәрьян***

*И минем җандай кадерлем,*
*И җылы, тере телем.*
*Кайгылар теле түгел син,*
*Шатлыгым теле бүген.*
*Тик синең ярдәм белән мин,*
*Тик синең сүзләр белән*
*Уйларын йөрәккәемнең*
*Дөньяга әйтә беләм.*

*Х. Туфан*

*Кил, өйрән, и туган, бер башка телне,*

*Бүтән телләр белү – яхшы һөнәрдер.*

*Катыштырма вә ләкин телгә телне,*

*Тел уйнатмак наданлыктан әсәрдер.*

***Тел дигән дәрья бар,***
***Дәрья төбендә мәрҗән бар.***
***Белгәннәр чумып алыр,***
***Белмәгән карап калыр.***

***Нәкый Исәнбәт***

Тел ачылгач , үз телеңдә әйтә алсаң
“Әни” дип,
Тел ачылгач , үз телеңдә әйтә алсаң
“Әти” дип,
Күзләреңә яшьләр тыгылмас,
Туган телең әле бу булмас.
Соң минутта үз телеңдә әйтә алсаң
“Әни” дип,
Соң минутта үз телеңдә әйтә алсаң
“Әти” дип,
Күзләреңә яшьләр тыгылыр
Туган телең әнә шул булыр.

*Зөлфәт*